**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.09.2020 № 959

«Алынмаган керемнәрне каплауга мунча хезмәтләре күрсәтүче оешмаларга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 21 ноябрендәге 967 номерлы карары белән расланган алынмаган керемнәрне каплауга мунча хезмәтләре күрсәтүче оешмаларга субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында (09.04.2020 № 398 номерлы карар редакциясендә)

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), индивидуаль эшкуарларга, шулай ук физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында» гы 2016 елның 6 сентябрендәге 887 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Кереп бетмәгән керемнәрне каплауга мунча хезмәтләре күрсәтүче оешмаларга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 21 ноябрендәге 967 номерлы карары белән расланган алынмаган керемнәрне каплауга мунча хезмәтләре күрсәтүче оешмаларга субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктта «мөһер белән беркетелгән» сүзләреннән соң «(булган очракта)» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлектәге 15 пунктны өстәргә:

«15. Субсидия бирү турында килешүне өзү түбәндәге очракларда мөмкин:

Алучының эшчәнлеген үзгәртеп оештыру яисә туктату;

Алучы тарафыннан Субсидия бирелүнең әлеге Тәртиптә билгеләнгән тәртибен, максатларын һәм шартларын бозу.

Субсидия бирү турында килешүне өзү Яклар килешүе буенча гамәлгә ашырыла һәм Субсидия бирү турында Килешүгә өстәмә килешү рәвешендә рәсмиләштерелә.».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад мәсьәләләре буенча урынбасары  М.Х.Хабибулловага йөкләргә

Җитәкче Р.М. Заһидуллин